**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт:
www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**КАРАР**

**2019 елның 18 декабре** **450№**

**Опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешманың эшчәнлеген контрольдә тоту тәртибен раслау турында**

2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы “Опека һәм попечительлек турында”гы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында" 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карарын гамәлгә ашыру турында" 2009 елның 14 сентябрендәге 334 номерлы боерыгы нигезендә, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1 Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балигъ булганнарның опекуннары яисә попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә тәрбияләү өчен гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшереп тору тәртибе турында Нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта)

2.Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балигъ булганнарның опекуннары яисә попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә тәрбияләү өчен гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешманың планлы тикшерүләр графигын расларга (2 нче кушымта).

3.Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://alkeevskiy.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче: И. В. Йосыпов

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
18 декабрендәге 450 номерлы Карарына
1 нче кушымта

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балигъ булганнарның опекуннары яисә попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә тәрбияләү өчен гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшереп тору тәртибе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип "Опека һәм попечительлек турында" 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон, балигъ булмаган гражданнарга мәгариф оешмалары, медицина оешмалары, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар яисә башка оешмалар,шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары белән расланган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар тарафына карата, опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 5 пунктын гамәлгә ашыру һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 235 номерлы боерыгы белән расланган Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибенең 24 пункты нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балигъ булганнарның опекуннары яисә попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә тәрбияләү өчен гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә теләк белдергән гражданнарны белән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органы вәкаләтләрен тапшыру турында шартнамәләр төзелгән оешмалар эшчәнлегенә контрольне гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

1.2. "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карарын гамәлгә ашыру турында" 2009 елның 14 сентябрендәге 334 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә сайлап алынган опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеген тикшереп тору Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшереп тору мондый оешма эшчәнлеген тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерүне үткәрү регламенты

2.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен башкару буенча оешма эшчәнлеген тикшерү, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтен үтәүче Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма

комитетының опека һәм попечительлек секторының вәкаләтле вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерүләр Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының бер вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яки комиссия составында берсе комиссия рәисе булган опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының кимендә ике муниципаль хезмәткәре тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

2.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерү планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

2.3.1. Планлы тикшерү булып Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган, тиешле календарь елга формалаштырыла торган һәм тикшерү планына кертелгән тикшерү тора.

2.3.2. Бер оешманы планлы тикшерү, гражданнарны балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән, я ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны тәрбиягә алырга әзерләү өчен юллама шартнамә нигезендә бирелгән очракта, елына бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

2.3.3. Планлы тикшерү оешманың урнашу һәм эшчәнлек алып бару урыны буенча (урынга чыгып тикшерү) үткәрелә.

2.4. Тикшерү планына кертелмәгән тикшерү планнан тыш тикшерү булып тора.

2.4.1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы Татарстан Республикасы Әлки район башкарма комитетының карары нигезендә түбәндәге очракларда планнан тыш тикшерү үткәрә:

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда гражданнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать итү;

- дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан һәм гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда оешма эшчәнлегендә, гамәлдәге законнар нормаларын бозулар турында мәгълүмат килү.

Планнан тыш тикшерү әлеге пунктта күрсәтелгән очраклар барлыкка килгәндә урынга чыгып яисә урынга бармый гына уздырыла.

2.5 Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен башкарганда оешма эшчәнлеген тикшергәндә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яки комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

- күрсәтелгән вәкаләтне гамәлгә ашыруга карамаган гамәлдәге законнар таләпләренең үтәлешен тикшерергә;

- тикшерү предметына карамаган документларны, мәгълүматны тапшыруны таләп итәргә;

- әлеге Тәртип белән билгеләнгән тикшерүне уздыру срокларыннан арттырырга.

2.6. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерү үткәрү максатларында, вазыйфаи зат (муниципаль хезмәткәр) тикшерүне үткәрү турында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмати хат оештыруны тәэмин итә:

- тикшерү формасы турында (урынга чыгып, урынга чыкмыйча);

- тикшерү төре турында (планлы, планнан тыш);

- тикшерү үткәрү вакыты турында (башлау һәм тәмамлау датасы).

Тикшерү үткәрү турында мәгълүмати хат оешмага тикшерү башланганчы 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.7 Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яки комиссия әгъзалары хокуклы:

- тикшерү максатына ирешү өчен кирәкле барлык документларны (мәгълүматны) соратып алырга, шулай ук тикшерү барышында килеп чыккан мәсьәләләр буенча язмача һәм телдән аңлатмалар таләп итәргә;

- тикшерү материалларына теркәп кую өчен тикшерү предметына кагылышлы документларның күчермәсен башкарырга.

2.8. Урынга чыгып (урынга барып тикшерү) тикшерү үткәрүнең гомуми срогы 2 (ике) эш көненнән артып китә алмый.

2.9. Күчмә тикшерү тәмамланган мизгелдән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары (муниципаль хезмәткәр) яки комиссия тарафыннан материалларны, документларны һәм аңлатмаларны өйрәнү нәтиҗәләреннән чыгып, тикшерү акты төзелә.

2.9.1. Тикшерү акты кәгазьдә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә.

2.9.2. Тикшерү актында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- тикшерү актын төзү датасы, тикшерү урыны һәм тикшерү үткәрү көннәренең санын күрсәтеп, тикшерү вакыты турында;

- тикшерү рәвеше һәм формасы турында;

- тикшерү үткәрергә нигез булган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының карары датасы һәм номеры турында;

- тикшерү үткәрелгән оешманың исеме турында;

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яки тикшерү үткәрүче комиссия әгъзалары турында (комиссия рәисен күрсәтеп);

- тикшерү үткәрү өчен оешма тарафыннан тапшырылган (тапшырылмаган) документлар (мәгълүмат) турында;

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен тормышка ашырганда оешма эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозу фактлары, аларның характеры һәм эчтәлеге турында;

- оешма тарафыннан опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлегендәге хокук бозу һәм житешсезлекләрне тикшерү тәмамланган вакытка бетерү турында;

- гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм тикшерү нәтиҗәләре турында йомгак;

- оешма җитәкчесен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырудан баш тарту яки таныштыру турында мәгълүматлар.

2.9.3. Тикшерү акты Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.Тикшерү актына комиссиянең аерым әгъзалары тарафыннан кул кую мөмкинлеге булмаган очракта, тикшерү актында тиешле имза булмау сәбәбен күрсәтеп тамга ясала.

2.9.4. Тикшерү актына тикшерүгә кагылышлы документлар яисә аларның күчермәләре, шул исәптән ачыкланган хокук бозулар өчен җавап бирүче оешманың вазыйфаи затларын аңлатулар кушып бирелә.

2.9.5. Тикшерү актының бер нөсхәсе оешма җитәкчесенә башкарма комитет җитәкчесе раслаган көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.10. Урынга чыкмыйча тикшерү Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яки комиссия

тарафыннанбулган документлар, шулай ук оешмадан сорала һәм алына торган документлар, оешманың вазыйфаи затларының аңлатмалары юлы белән үткәрелә.

2.10.1. Оешма җитәкчесе тикшерү үткәрү турында мәгълүмат хатында күрсәтелгән срокта гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлегенә кагылышлы соратып алынган барлык документларны тапшырырга тиеш.

Урынга чыкмыйча гына тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет тарафыннан белешмә әзерләнә. Белешмәгә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары имза сала, Татарстан Республикасы Әлки район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан килештерелә. Белешмә заказлы хат белән оешмага Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе килештергән вакыттан алып 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
18 декабрендәге 450 номерлы Карарына
2 нче кушымта

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балигъ булганнарның опекуннары яисә попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә тәрбияләү өчен гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешманың планлы**
**ТИКШЕРҮЛӘР ГРАФИГЫ**

| Тикшерү ешлыгы | Тикшерү үткәрү ае | Тикшерү үткәрү датасы | Тикшерү уздыру срогы |
|---|---|---|---|
| Елга 2 тапкыр | Апрель<br>Октябрь | Айның беренче атнасы | 2 көн |